Казан шәһәре Идел буе районының «Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә торган 10 нчы татар-рус урта гомуми белем мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениясе

Килешенде:
Тәрбия эшләре буенча
директор урынбасары
Мингазова Д.А.
Протокол №1
“29” август 2023ел

Раслыйм:
Мәктәп директоры
Нургатина А.Р.
Приказ №207
“29”август 2023ел

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

Сертификат: 59641A2234504E652E979A5CB15D1F31
Владелец: Нургатина Алсу Рамилевна
Действителен: с 03.10.2023 до 26.12.2024

# “ ХЫЯЛ”

8 нче сыйныфларда укучы балалар өчен
түгәрәк эше программасы

Төзеде: туган (татар) тел
һәм әдәбияты укытучысы
Хадиева Фәридә Ильдус кызы

2023-2024 нче уку елы

## Аңлатма язуы

Бу түгәрәк укучыларның артистлык сәләтен, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен, логик фикерләүләрен үстерү максатыннан чыгып оештырыла. “Хыял” драма түгәрәге, исеменнән үк күренгәнчә, театр, сәнгать, җыр-бию яратучы укучылар өчен оештырылды. Бу түгәрәк шулай ук сәхнә серләренә төшенү, тамашачылар алдында үз-үзеңне тотарга өйрәнү бурычларын үз эченә ала.

Түгәрәктә сәләтле балалар белән күмәкләп, шулай ук индивидуаль эшләү дә урын алган. Мәктәбебездә сәнгать сөюче балалар бик күп. Шундыйларны сайлап алып һәм теләк-хыялларын истә тотып эшләү уңышлы булыр дигән фикергә килдем.

Һәр халык үзенә хас булган, гореф-гадәтләргә бай. Татар халкының, башка халыклар кебек үк тарихы, үткәне бик бай, йола-бәйрәмнәре һәм уеннары да күп төрле.

Түгәрәк программасын төзегәндә, укучыларны шушы халык бәйрәмнәре һәм йолалары үрнәгендә тәрбияләү, җыр-биюләрне, такмак-такмазаларны өйрәтү, шулар аша дуслык хисләре тәрбияләү, милли хисләр, туган җиргә мәхәббәт хисләре тәрбияләү алгы планга куелды.

Түгәрәктә йөрүче укучыларны балалар шагыйрьләре, әсәрләре белән тирәнрәк тыныштыру, аларның әсәрләрен күбрәк уку теләге уяту максатлары да күздә тотылды.

Укучылар шулай ук үткән темалар ярдәмендә иҗади эш итеп шигырь, әдәби әсәр укырга өйрәнеп, сәхнәдә күрә белү, тыңлый һәм ишетә белү күнекмәләрен үстерә ала.

Түгәрәк дәресләрендә татар теле, әдәбияты, рәсем, җыр сәнгате, уеннар һәм сәхнә әсәрләре бәйләнештә бирелә. Дәресләр халкыбызның гореф-гадәтләрен, әдәбиятын, мәдәниятын өйрәнүгә нигезләнә. Әлеге программага нигезләп үткәрелгән түгәрәк эше укучыларга ярдәм итәр, матур сөйли, аралаша, үз фикерләрен эзлекле әйтергә өйрәтер дип ышанам. Укучыларның активлыгын, иҗади эшчәнлеген, кызыксынучанлыгын үстерүгә күнекмәләр формалаштыруга төрле иҗади биремнәр, күнегүләр бирелә, эзләнү методы кулланыла. Программа 171 сәгатькәисәпләнгән.

## Түгәрәкнең максаты:

Шәхес формалаштыруга юнәлтелгән технология аша укучыларда әдәбиятка-сәнгатькә мәхәббәт тәрбияләп, иҗади үсешләрен булдыру, Һөнәри омтылышларын, сәләтләрен ачарга, матур сөйли, үз фикерләрен эзлекле әйтергә өйрәтү. Театр сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләү.

**Үстерелешле максат:**

1. Сәнгатьле уку һәм сөйләм кунекмәләрен үстерү.
2. Иҗади сәләтләрен үстерү һәм тирәнәйтү.
3. Сәхнә осталыгын үстерү өстендә эшләү

**Түгәрәкнең бурычлары:**

- Укучыларны түгәрәк эшенә җәлеп итү, театр белән кызыксыну уяту.
- Сәнгать әсәрләренә мәхәббәт уяту.
- Укучыларның артистлык сәләтен, иҗади талантларын күрә, уңышларга дәрт уята алуга ирешү.

- Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү.
- Аеруча балалар өчен язылган һәм классик әсәрләр сәхнәләштерү, иҗат итү.
- Төрле бәйге-ярышларда чыгышлар ясау.
- Сүз сәнгатеннән алган белемнәрен тагы да тирәнәйтү, гомумиләштерү.

- Акыл үсеше белән сөйләм теленең үсешен үстерү, персонажлар сөйләмен сәнгатьле итеп сөйләү өстендә эшләү, баланың сүз байлыгын арттыру, интонацияле сөйләү тәрбияләү;
- хәрәкәт күнекмәләрен формалаштыру;
- сәхнәләштерү эшчәнлегенә тотрыклы кызыксынуны үстерү;
- мимика, ишарәләр, хәрәкәтләр, интонация тәэсирле чараларын кабатлау теләге тудыру;
- музыка һәм хореография сәнгате нигезләре белән танышу;
- укучыларда эстетик, әхлак һәм хезмәт тәрбиясен тормышка ашыру;
- сәнгатькә кызыксыну һәм мәхәббәт тәрбияләү.

Түгәрәк дәресләре төрле формада уткәрелә. Күбрәк теоретик һәм практик юнәлештә эш башкарыла. Дәрес-әңгәмә, дәрес-очрашу, дәрес-экскурсияләр үткәрү дә күздә тотыла. Төп игътибар балаларның иҗади сәләтен үстерүгә, аларны милли җанлы, милли рухлы итеп тәрбияләүгә, сәнгатьле һәм образлы сөйләм формалаштыруга, мөстәкыйль шәхес үстерүгә, әзерләүгә юнәлтелә.

**Көтелгән нәтиҗәләр һәм аларны тикшерү төрләре.**

1. Театр сәнгатен башка сәнгать төрләреннән аеру.
2. Татар театры тарихы, уткән юлы белән танышу.
3. Сәнгатьле сөйли, образга керү.
4. Актерлык талантына ия.
5. Иҗади һәм мөстәкыйль эшли, үз киңәшләрен башкаларга да бирә ала.
6. Драма төрләрен аера, классик әсәрләрне аңлый.
7. Сәхнә тормышы белән таныш, башка милләт театрлары белән дә кызыксыну.

**“Хыял” драмтүгәрәге программасының актуальлеге:** Кереп баручы стандартларының яңалыгы – белем һәм тәрбия алуда универсаль гамәлләрнең берсе коммуникатив гамәлләрнең камил формалашуы. Ягъни, баланың үз фикерен диалогта һәм монолог рәвешендә башкаларга дәлилле итеп, әңгәмәдәшен кимсетмәслек итеп җиткерә белүгә әзерләү. Бу таләп – түгәрәкнең актуальлеген раслаучы мөһим дәлилдә. Балаларны берләштерүдә, зурлар белән аралашуга өйрәтүдә, сөйләм телен үстерүдә, җәмгыятьтә үзен-үзе тота белеп, актив һәм сәләтле кеше булып үсүендә сәхнәләштерү эшчәнлегенең әһәмияте бик зур.

1. Балаларның милли культура, театр, артистлар дөньясы турында күп мәгълүмат белүе.
2. Сәхнәләштерү уеннарын үзләштерү ярдәмендә балаларның интонацияләре яхшыру, башка катнашучылар белән аралашу осталыклары арту, килешү, конфликтлы ситуацияләрне чишә белү мөмкинлекләре туу. Балаларның бәйләнешле сөйләм телләре үсү.
3. Сәхнә тормышында үзеңне иркен тоту күнекмәләренә төшенү
4. Сәнгать кешеләре турында мәгълүмат алу.
5. Практика белән теорияне кушып, тулыландыра алу мөмкинлеге булу.
6. Гаилә белән мәктәп арасында җылы мөнәсәббәт тудыру
7.

**Тематик планлаштыру**

| № | Эш төре | Теоретик сәг. саны | Практик сәг. саны | Число |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Кереш. Түгәрәкнең эш планы белән таныштыру. Инструктаж үткәрү. | 2 | | .09 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2. | Театр турында төшенчә. Театр сәнгатенең төп үзенчәлеге. | 2,5 | | .09 |
| 3. | Татарстандагы театрлар һәм ”Театр-минем тормышым” дигән хезмәт белән танышу. | 2 | | .09 |
| 4. | Театр структурасы. Һөнәрләр:актер, режиссер, гример, рәссам һ.б. | 7 | | .09<br>.09<br>.09 |
| 5. | Сәхнә бизәлеше һәм техник чаралар.Сәхнә серләренә өйрәнү.Видеоязмалар карау. | 4,5 | | .09<br>.09 |
| 6. | Ритмопластия. Музыка. | 2 | | .10 |
| 7. | Эскиз бизәкләре. Костюмнар. Киенү-бизәнү осталыгы. | 2,5 | 2 | .10<br>.10 |
| 8. | Сөйләм культурасы һәм техникасы. Сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү. | 2,5 | 2 | .10<br>.10 |
| 9. | Интонация. Дикция. | | 2,5 | .10 |
| 10. | Сөйләм сулышы һәм артикуляциясе. Диафрагма. | 2 | 2,5 | .10<br>.10 |
| 11. | Сөйләм логикасы. | 2 | | .11 |
| 12. | Образлы сөйләм. | 2 | 5 | .11<br>.11<br>.11 |
| 13. | Рифмалар. | 2 | | .11 |
| 14. | Сүз байлыгын тулыландыру. | 2,5 | 2 | .11<br>.11 |
| 15. | Хикәя һәм әкиятләр язу. Иҗади сәләтне үстерү | 2,5 | 2 | .11<br>.11 |
| 16. | Рольләргә бүлү. Репетиция | | 7 | .12<br>.12<br>.12 |
| 17. | Премьера. | | 2 | .12 |
| 18. | Шигырьләрне сәнгатьле уку. Х.Туфан, Х.Такташ шигырьләре. | 2 | 2,5 | .12<br>.12 |
| 19. | Т.Миңнуллин “Кәрлә-мәктәп баласы”. Рольләрне бүлү. Сүзләрне ятлау серләре. Киенү-бизәнү осталыгы. Актерлык талантын ныгыту. | 2 | 16 | .12<br>.12<br>.12<br>.01<br>.01<br>.01 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | .01 |
| 20. | К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия артистлары белән очрашу. | 2 | дәрес-очрашу | .01 |
| 21. | Театр культурасы нигезләре. | 2,5 | | .01 |
| 22. | Театр һәм тамашачы. | 2 | | .01 |
| 23. | Ишетү, күрү, хәтер, фикер йөртү сәләтен үстерү. | | 2,5 | .01 |
| 24. | Жест, мимика, хәрәкәт. | | 2 | .02 |
| 25. | Этюд хәрәкәтләре. | | 2,5 | .02 |
| 26. | Г.Камал “Беренче театр” комедиясен карау. Образларга сыйфатлама бирү. | | 2 | .02 |
| 27. | Г.Камал исемендәге Татар Дәүләт академия театрына экскурсия. | | 2,5 | .02 |
| 28. | Туган телләр атналыгында катнашу. | | 2 | .02 |
| 29. | М.Сәлимҗанов исемендәге бәйгедә катнашу. | | 2,5 | .02 |
| 30. | Татар халык шагыйре Г.Тукайның “Театр”шигырен сәнгатьле уку.Силлабик шигырь һәм гарузны уку үзенчәлекләре. | 2 | | .02 |
| 31. | Беренче драматурглар: Г.Ильяси, Ф.Халиди, Г.Камал, К.Тинчурин. | 2,5 | | .03 |
| 32. | Беренче театр труппалары: “Сәйяр”,”Нур”, “Аң” | 2 | | .03 |
| 33. | Театрда режиссер хезмәте. Г.Камал һәм М.Сәлимҗанов иҗаты. | 2,5 | | .03 |
| 34. | Нәрсә ул импровизация? Викторина. | | 2 | .03 |
| 35. | Шәһәр театр фестивалендә катнашу | | 2,5 | .03 |
| 36. | Театр тарихында урын алган артистлар. Ш.Биктимеров,Н.Гараева,Р.Шәрәфиев, И.Мәхмүтова,Н.Ихсанова һ.б. | 2 | | .03 |
| 37. | Партнер белән бирелгән темага диалог төзү. | | | .03 |
| 38. | Драма әсәрләренең төрләре. Комедия. Драма.Трагедия. Драма әсәрләреннән өзекләр карау. | 2 | | .03 |
| 39. | Сәхнә культурасы. | 4,5 | | .03<br>.04 |
| 40 | Мәгънәви паузалар.Ритмик пауза.Психологик. | 2,5 | 2 | .04 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Физиологик киеренкелек тудыручы пауза. | | | .04 |
| 41 | Проза әсәрләрен сәнгатьле уку күнегүләре.<br>Текст белән эш. Ә.Еники хикәяләре. | 2,5 | 2 | .04<br>.04 |
| 42 | Сөйләм тизлеге.Такмаклар, тел шомарткычлар турында мәгълүмат һәм өйрәнү. | | 2,5 | .04 |
| 43 | Шигьри әсәрләрне сәнгатьле уку. Шигырьдә ритм. А.Арсланов, И.Әхмәтҗәнов<br>башкаруында аудиоязмалар<br>тыңлау. | 2 | 2,5 | .04<br>.04 |
| 44. | Тыныш билгеләре. Игътибарлы итеп укырга күнектерү. Иҗади эш. | | 2 | .05 |
| 45. | Аралашу кагыйдәләре. Коммуникатив хаталар.Төрле ситуацияләрне анализлау, сәбәпләрен күрсәтү. Телефоннан сөйләшү. | | 2 | .05 |
| 46. | Милли музейга сәяхәт | дәрес-экскурсия | 2,5 | .05 |
| 47. | “Туган як шагыйрьләре шигырьләр дөньясында”<br>Әдәби –музыкаль композиция. | | 4,5 | .05<br>.05 |
| 48. | Беренче татар профессиональ театрына нигез салучылар: С.Гыйззәтуллина-Волжская, Г.Кариев. | | 2 | .05 |
| 49. | Татар сүз сәнгатенең күренекле вәкилләре.<br>Укучыларның проект эшләре | | 4,5 | .05<br>.05 |
| 50. | Эшләгән эшләргә нәтиҗә ясау.Уңышларым һәм җитешсезлекләрем.Укучыларның үз-үзләренә бәя бирүләре. | | 2 | .05 |

**Кулланма әдәбият:**


1. Хаков В.Х.Татар милли әдәби теле формалашу чорында драма әсәрләренең теле//Татар тел белеме мәсьәләләре. – Кит. 3 – Казан, 1969
2. С.Ш.Поварисов. Тел – күңелең көзгесе. Казан Татарстан китап нәшрияты, 1982
3. Нуриев Г.-Р. С. Татар сәхнә сөйләме: Монография. – Казан: Татар “Мирас” кит. нәшр., 1998
4. Нуриев Г.-Р. С. Сәнгатьле уку. Методик ярдәмлек. – Казан: 2000
5. Нуриев Г.-Р. С., Хәйруллина А.Х. Сәхнә теле. – Казан: “Отечество” нәшр., 2004